ГЛАВА НИЖНЕТАКАНЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Банковская, д.17, с. Нижний Таканыш, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422140

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН ТӘКӘНЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Банк ур., 17 нче йорт, Түбән Тәкәнеш авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422140

тел.(факс): (85563) 2-63-21; e-mail: Nakt.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар
"08 " ноябрь 2019 ел.

Постановление
№ 9

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлегенең Түбән Оча авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге" Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм :

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Түбән Оча авылы, Мәктәп урамы, 9 нче йорт адресы буенча урнашкан Түбән Оча авылы авыл клубы бинасында 2019 елның 20 нче ноябре 15.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлегенең Түбән Оча авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлегенең Түбән Оча авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннар, көндезге бүлектә белем алучы студентлар кала, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Түбән Оча авылы торак пункты урамнарын ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Түбән Оча авылы торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;

-Түбән Уча авылы зираты территориясендә хуҗалык төзелеше (материаллар сатып алу, төзелеш, килешү буенча эш өчен түләү)

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге башкарма комитетына Түбән Оча авылы торак пунктында гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә .

4. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 3 көн эчендә муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге башлыгы: Р.Җ.Хәмизуллин